Утверждаю
директор МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №3»
г.Альметьевска Республики Татарстан
__________ Л.А.Казаринова

Приказ №277 от 28.10.2017 г.

# Приложение №4
# к основной образовательной программе основного общего образования (ФГОС ООО)
# муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная школа №3» г. Альметьевска Республики Татарстан

**1. Раздел 1.2.5.3. Татарский язык и литература основной образовательной программы основного общего образования изложить в следующей редакции:**

**1.2.5.3. Родной (татарский) язык и литература**

**Родной (татарский) язык (для русскоязычных групп)**

Татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- “Татар теле” предметынакарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Тыңлап аңлау**

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

**Диалогик сөйләм**

Сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

**Монологик сөйләм**

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

**Уку**

Уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

**Язу**

Өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;

конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;

үзеңне борчыган проблемага карата үз фикерләреңне язмача җиткерә белү;

тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

**Родная (татарская) литература (для русскоязычных групп)**

Рус телендә сөйләшүче укучыларның 5-9 сыйныфта төп гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар әдәбиятын үзләштерү нәтиҗәсендә белем һәм күнекмәләрен камилләштерергә, үзаңнарын үстерергә, рухи-әхлакый сыйфатларын һәм эстетик зәвыкларын формалаштырырга, тормышта һәм тирәлектә үз урыннарын табарга ярдәм иткән күнекмәләр түбәндәгеләр.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**

Россия гражданинына хас сыйфатлар булдыру; Туган илгә карата хөрмәт һәм мәхәббәт, горурлык хисләре тәбияләү, татар халкының һәм Татарстанда яшәүче барлык халыкларның тарихына, теленә,мәдәниятенә ихтирам хисләре булдыру; күпмилләтле Россия җәмгыятенең гуманистик һәм традицион кыйммәтләрен үзләштерү; Туган ил алдында җаваплылык һәм бурычлылык сыйфатларын тәрбияләү;

иҗтимагый, мәдәни, рухи үсешне истә тоткан, чорның фәнни үсешенә, гамәли эшчәнлеккә тәңгәл килгән күзаллау булдыру;

Россиядә һәм бөтен дөньяда яшәүче халыкларның карашларына, мәдәниятенә, теленә, диненә, гражданлык позициясенә аңлы рәвештә хөрмәт белән карау;

Укучыларның үзлегеннән белем алуга, танып белүгә әзер булуы, аңлы рәвештә һөнәр сайлауга килүе;

Уку эшчәнлеген мөстәкыйль оештыру; укуда ирешкән казанышларыңны, иҗтимагый тирәлектә үз – үзеңне тотышыңны, шәхси сыйфатларыңны, рухи халәтеңне бәяли белү; күпмилләтле мохиттә уртак эшчәнлек алып бару күнекмәләре булдыру; әхлак нормалары һәм эстетик кыйммәтләр югарылыгыннан үз – үзеңә бәя бирү; күпмилләтле һәм күп конфессияле дәүләттә үзеңнең гражданлык хокукларыңны белү һәм бурычларыңны үтәү;

Иҗтимагый урыннарда гомумяшәеш нормаларын, кагыйдәләрен үзләштерү; мәктәпнең иҗтимагый тормышында, үзидарә органнарында катнашу;

Үз холкыңа, үз-үзеңне тотышыңа әхлак нормалары югарылыгыннан бәя бирү;

Иҗтимагый, белем алу, уку – тикшеренү, иҗади һәм башка эшчәнлек вакытында үз яшьтәшләрең, өлкәннәр һәм яшьләр белән аралашу компетентлыгы булдыру;

Тирә – юньгә игътибарлы булу,экологик культура сыйфатлары формалаштыру;

Җәмгыятьтәге барлык кешеләргә,шул исәптән гаилә әгъзаларына хөрмәт һәм ихтирам хисләре белән карау;

Татарстан, Россия һәм бөтендөнья халыкларының сәнгати һәм мәдәни мирасын үзләштерүаша матурлык сыйфатларын үстерү.

**Метапредмет нәтиҗәләре**

Мөстәкыйль рәвештә уку мәсьәләләрен кую, укуда һәм танып белүдә яңа максатларга омтылып яшәү;

Мөстәкыйль рәвештә максатка ирешү юлларын планлаштыру; кылган гамәлләрне ирешәчәк нәтиҗә беләнчагыштыра белү;

Үзконтроль, үзбәя нигезләрен үзләштерү, уку һәм танып белүдә аңлы рәвештә сайлап ала белү
Уку һәм танып белү мәсьәләләрен куюда тамгалар, символлар, модельләр, схемалар файдалана алу;
Үз хисләреңне, фикерләреңне, ихтыяҗларыңны канәгатьләндерү өчен аралашу бурычын чишкәндә, тел һәм сурәтләү чараларыннан аңлы рәвештә файдалану, әдәби әсәрне уку һәм асыл мәгънәсен аңлау;
Аралашу тибына һәм төрле очракларга бәйле рәвештә,бәйләнешле сөйләм күнекмәләре булдыру;
Мәгълүмати- коммуникатив технологияләрне файдалану өлкәсендә компетентлыкны формалаштыру һәм үстерү.

**Предмет нәтиҗәсе**

Үзләштерелгән татар фольклоры, Россия һәм дөнья халыклары фольклорының, татар классик һәм хәзерге әдәбиятның әдәби багланышларның төп мәсьәләләрен (проблемасын) аңлау;
Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны аңлап, йөгерек уку; текстның асыл мәгънәсен аңлау, укуның төрләрен (күзәтү, эзләнү һ.б.) куллану;
Әдәби әсәргә бәя биргәндә, элементар әдәби терминологиядән файдалана белү;
Проза әсәреннән алынган элемтәләргә таянып, әсәрнең яки аның өзегенең эчтәлеген сөйли белү; тыңланган яки укылган текст буенча сорауларга җавап бирә алу:
Төрле халыкларның фольклоры һәм әдәби әсәрләре арасында тема, проблемалар, образлар системасына бәйле рәвештә уртак һәм аермалы якларны күрә һәм ачыклый белү;
Төрле дәрәҗәдәге анализ эшенә өйрәнү максатыннан, мөстәкыйль рәвештә (яки укытучы җитәкчелегендә) татар әдәбияты һәм башка халыклар, этник төркемнәр әдәбиятын чагыштыру күнекмәләре булдыру;
Монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләре булдыру; сөйләшүдә катнашу; диалогта катнашу (әңгәмәдәшеңнең фикерен аңлау һәм җавап бирү, үз фикерен дәлилләү); тыңланган һәм укылган мәгълүматны төгәл файдаланып, фикерне язмада чагылдыру;
Коммуникатив бурычка, аралашу даирәсенә һәм очрагына бәйле рәвештә, телнең сәнгатьчә чараларыннан файдалану; танып белү һәм коммуникатив бурычларны чишү өчен, төрле мәгълүмати чаралардан, аерым алганда, энциклопедия, сүзлекләр, Интернет мөмкинлекләреннән һәм башка чыганаклардан файдалана белү;
Уку процессында, ягъни гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне иркен файдалану.

**Родной (татарский) язык (для татароязычных групп)**

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

**Аралашу компетенциясе** – барлык сөйләм эшчәнлеге төрләренә ия булу, башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар әдәби телендә телдән һәм язма формада ирекле аралашу, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру; сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; урта сыйныф укучыларына хас булган кызыксыну даирәсенә, психологик һәм төрле аралашу ситуацияләренә бәйле рәвештә туган телдә аралаша белү, дәресләрдә үзләштергән белем һәм күнекмәләрдән нәтиҗәле итеп файдалану.

**Лингвистик компетенция** – тел белеме, аның төзелеше, үсеше һәм функциясе турындагы белемнәрне системалаштыру, лингвистик анализ ясый белү; тел белеме һәм аның бүлекләре буенча гомуми мәгълүматлылык; татар әдәби теленең төп нормаларына ия булу, укучыларның сүзлек байлыгының, сөйләмнәренең грамматик төзелешенең камиллеге; төрле лингвистик сүзлекләрдән ирекле файдалана алу.

Телгә өйрәткәндә, **аралашу эшчәнлегенә карагануниверсаль** күнекмәләрдән түбәндәгеләрне булдыруга һәм үстерүгә өстенлек бирелә:
төркем белән эшләү күнекмәләре алу. Укучының иптәшләре һәм укытучы белән бергәләшеп эшләү күнекмәләренә ия булуы балаларны мораль-әхлакый һәм психологик яктан да гамәли эш алымнарына өйрәтә;
аралашу компетенциясе төрле бурычларны хәл итү алымнарын үзләштерү, телне өйрәнү башка кешеләр белән аралашуның нигезен тәшкил итүен истә тотарга да өйрәтә, шул максаттан тормыш хәлләренә бәйле рәвештә иптәшең белән аралашу нормаларын һәм формаларын үзләштерүне дә күз уңында тота;

телне өйрәнү сөйләм эшчәнлеген үстерүне дә алгы планга куя, бу исә укучыларның ана телен өйрәнгәндә аралашу компетенциясен истә тотып эш итәргә этәргеч ясый.

**Этнокультура өлкәсенә караган компетенция,** ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү — укучыларны сөйләмгә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү; тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү; татар сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү, шулар аша халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен аңлау, телнең милләтләр арасында аралашу-аңлашу чарасы булуына төшенү; тел тарихы белән халык тормышының аерылгысыз булуын күзаллау.

Шуның белән беррәттән, аралашу эшчәнлегенә караган универсаль күнекмәләрдән түбәндәгеләрне ассызыклап китү урынлы булыр:

төркем белән эшләү күнекмәләре алу. Укучының иптәшләре һәм укытучы белән бергәләшеп эшләү күнекмәләренә ия булуы балаларны мораль-әхлакый һәм психологик яктан да гамәли эш алымнарына өйрәтә;

аралашу компетенциясе төрле бурычларны хәл итү алымнарын үзләштерү, телне өйрәнү башка кешеләр белән аралашуның нигезен тәшкил итүен истә тотарга да өйрәтә һәм шул максаттан тормыш хәлләренә бәйле рәвештә иптәшең белән аралашу нормаларын һәм формаларын үзләштерүне дә күз уңында тота;

телне өйрәнү сөйләм эшчәнлеген үстерүне дә алгы планга куя, бу исә укучыларның ана телен өйрәнгәндә аралашу компетенциясен истә тотып эш итәргә этәргеч ясый.

Бу җәһәттән, татар телен өйрәнгәндә, укучыларның универсаль танып-белү гамәлләрен булдыру һәм камилләштерү алдагы **нәтиҗәләргә** китерә:

балалар проектлау-тикшеренү күнекмәләрен гамәли яктан үзләштерәләр;

мәгънәсенә төшенеп уку һәм алган мәгълүмат белән эшли белү күнекмәләре бирелә;

танып-белү методын гамәли яктан куллана белергә өйрәтә, бу яктан тел өйрәнү дәресләрендә укучылар логик фикерләү алымнарына да ия булалар.

Башлангыч сыйныфта алган, үзләштерелгән мәгълүмат белән эшләү күнекмәләре 5-9 нчы сыйныфларда тагын да камилләштерелә һәм үстерелә. Бу уңайдан түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелә:

әзер мәгълүмат чыганакларындагы фикерләрне системага салып, чагыштырып, тикшереп һәм гомумиләштереп, мөстәкыйль аңлатмалар бирергә өйрәнелә;

аерым текстлар белән эшләгәндә, төп фикерне аерып алып, аны тезис рәвешендә кыска, җыйнак һәм төгәл итеп, график (таблица, схема, карта яки диаграмма) формасында җиткерү;

булган таблица, схема һәм график рәсемнәрне тутыра яки тулыландыра белү. Моның өчен тел дәресләрендә мәгълүматны төрле чыганаклардан һәм заманча техник чаратлар ярдәмендә эзләп табарга өйрәтү, Интернет челтәреннән урынлы, чамасын белеп һәм дөрес итеп файдалану.

Укучыларның танып-белү компетенциясен үстерүдә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү күздә тотыла:

ана теле дәресләрендә укучылар туган илнең тарихи-географик образын күзаллый белергә, шуңа бәйле рәвештә туган ягының тарихын һәм географиясен, аның мәдәни мирасын һәм традицияләрен күзаллый белү;

тел дәресләрендә үтелә торган темаларга бәйле рәвештә туган илнең иҗтимагый-сәяси төзелешен, анда булып узган тарихи вакыйгаларны хронологик һәм фактик яктан белергә бурычлы; шуңа бәйле рәвештә дәүләт символлары булып саналган герб, флаг һәм гимнны, дәүләт бәйрәмнәрен дә белү;

илнең гражданнары буларак, укучылар үзләренең хокук һәм бурычларын, милли традицияләрен, мәдәниятларын, аның кыйммәтләрен аңлау һәм белү.

**Тел системасы**

***“Фонетика. Орфоэпия. Графика”*** бүлегендә төп һәм югары сыйныфларда укучылар түбәндәгеләрне үзләштерә:

- сүзләргә фонетик анализ ясарга өйрәнә;
- татар теленең орфоэпик кагыйдәләрен саклап сөйләшүнең мөһимлеген аңлый;
- татар теленең орфоэпик сүзлегеннән төрле белешмәләрдән кирәклек мәгълүматны табып, аларны тиешле урында дөрес итеп кулланырга өйрәнә.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:

- фонетиканың төрле сәнгатьле уку чараларын аеру;

- проза һәм поэзия жанрына караган текстларны сәнгатьле итеп уку;
- мультимедия формасындагы орфоэпик сүзлек һәм белешмә материаллардан кирәкле мәгълүматны эзләп табып, аны үзенә кирәк вакытта файдалана белү.

***“Морфемика һәм сүз төзелеше”*** бүлегендә укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:
- сүзне морфемаларга бүлә;
- өйрәнелгән сүз ясау ысулларын билгели;
- бирелгән сүздән (тамырдан) төрле сүзләр ясый;
- морфемика һәм сүз ясалышын өйрәнү укучыны дөрес язарга, сүз төркемнәрен һәм җөмлә кисәкләрен танырга ярдәм итә.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:
- тамырдаш сүзләр арасындагы мәгънә бәйләнешен һәм чылбырын күрү;
- әдәби текстларда сүз ясау элементларының сурәтләү чарасы буларак та әһәмиятен аңлау;
- сүз ясалуга караган сүзлекләр һәм белешмә материалдан (мультимедия чараларыннан) кирәкле мәгълүматны табу;
- сүзнең дөрес язылышын һәм лексик мәгънәсен аңлату өчен, аның этимологик ягына игътибар итү.

***“Лексикология һәм фразеология”*** бүлегендә укучылар түбәндәгеләрне үзләштерә:
- сүзләргә лексик анализ ясый (мәгънәсенә бәйле позицияләрне ачыклый; аңа килеп чыгышы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу дәрәҗәсе ягыннан чыгып бәя бирә);
- сүзләрне тематик төркемнәргә берләштерә;
- сүзләрнең синонимнар һәм антонимнар таба;
- фразеологик әйтелмәләрне таный;
- телдән һәм язма сөйләмдә лексик нормаларны саклый;
- лексик синонимия күренешен кирәкмәгән кабатлаулардан саклау һәм сөйләмне бәйләнешле итү чарасы буларак файдалана;
- сүзнең күчерелмә мәгънәсенә бәйле сурәтлү чараларын – метафора, эпитет, сынландыруны билгели;
- төрле лексик сүзлекләрдән (аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, фразеологик) тиешенчә файдалана;

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:
- татар теленең сүзлек составына гомуми классификация ясау;
- сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен аеру;
- төрле омонимнарны тану;
- үзенең һәм иптәшләренең сөйләмен төгәллеге, сүзләрне урынлы һәм сәнгатьле итеп куллана белүе ягыннан бәяләү;
- публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда лексик-фразеологик чараларны таный, фәнни һәм махсус эш стилендә кулланыла торган лексик чараларны белү;
- төрле лексик сүзлекләрдән (аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, чит тел сүзләре, фразеологик) һәм мультимедия чараларыннан кирәкле мәгълүматны эзләп табу.

***“Морфология”*** бүлегендә укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:
- татар телендәге сүз төркемнәрен аера белә;
- аерым сүз төркеменә керүе ягыннан (морфологик яктан) сүзләрне тикшерә;
- сүз төркемнәренең төрле формаларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында куллана;
- морфологик белем һәм күнекмәләрне сүзләрнең дөрес язылышына, башка төрле анализларга бәйле рәвештә куллана.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:
- укучы морфологиянең сүзлек составын тикшерү;
- грамматик омонимнарны аеру;
- публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда морфологик берәмлекләрне тану, фәнни һәм махсус эш стилендә кулланыла торган морфологик формаларны белү;
- төрле сүзлекләрдән һәм мультимедия чараларыннан морфологиягә кирәкле мәгълүматны эзләп табу.

***“Синтаксис”*** бүлеге түбәндәгеләрне күз алдында тота:

- укучы синтаксисның төп берәмлекләреннән сүзтезмә һәм җөмләләрне, аларның төрләрен аерырга өйрәнә;
- сүзтезмә һәм җөмләләрне төзелеше һәм мәгънәләре, кулланылу үзенәлекләре ягыннан тикшерә;
- сүз төркемнәренең төрле синтаксик формаларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында куллана;
- укучылар синтаксистан булган белем һәм күнекмәләрен башка төрле анализлар вакытында да куллана белә.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:

- публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда синтаксик чараларны тану, фәнни һәм махсус эш стилендә кулланыла торган синтаксик чараларны белү;
- синтаксик конструкцияләрне функциональ-стилистик үзенчәлекләре ягыннан тикшеү, аларның сөйләмне сәнгатьле итү чарасы булуын аңлау.

***“Орфография һәм пунктуация»***бүлегендә укучы:

- язуда орфографик һәм пунктуацион нормаларны өйрәнелгән күләмдә файдалана;
- сүзнең дөрес язылышын телдән сөйләү яки язма рәвештә аңлата;
- орфографик һәм пунктуацион хаталарны таба һәм төзәтә;
- орфографик сүзлекләрдән һәм белешмәләрдән кирәкле мәгълүматны таба һәм аларны язуда куллана.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:

- сөйләмдә орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклауның әһәмиятен күрсәтү;
- орфографик сүзлекләрдән һәм белешмәләрдән (мультимедия чараларыннан) кирәкле мәгълүматны табу һәм аларны язуда урынлы итеп куллану.

***“Стиистика”*** бүлегендә укучы:

- функциональ (фәнни, махсус эш һәм публицистик) стильләр белән таныша, аларның жанр үзенчәлекләрен билгели;
- аудитория (иптәшләре) алдында чыгыш ясарга өйрәнә: аның темасын билгели, максат һәм бурычларын күрсәтә;
- тел чараларын тыңлаучыларның яшь, психологик үзенчәлекләрен һәм сайланган темангың белем дәрәҗәсенә туры килүен һ.б. истә тотып сайлый.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:

- телдән һәм язма сөйләм арасындагы үзенчәлекләрне аңлый һәм аңлата белә;
- төрле стиль һәм жанрга караган текстлар белән эшли (аларны билгеләнгән максаттан чыгып укый, мәгълүмати яктан кисәкләргә бүлеп эшкәртә);
- төрле характердагы текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итә, бу вакытта телдән һәм язма сөйләм нормаларын саклап эш итә.

***“Тел һәм мәдәният”*** бүлегендә укучы:

- милли-мәдәни компонентка ия булган тел берәмлекләрен халык авыз иҗаты әсәрләреннән, тарихи темаларга язылган һәм матур әдәбият әсәрләреннән аерып ала;
- телне өйрәнү ил тарихын һәм мәдәниятен яхшырак белергә ярдәм итә дигән фикерне раслардай мисаллар таба;
- көндәлек тормышта һәм укуда татар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен белеп һәм тиешенчә куллана.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:

- телнең халык мәдәнияте һәм тарихы белән аерылгысыз бәйләнештә булуын аерым мисаллар ярдәме белән тасвирлау;
- татар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен Россиядә яшәүче башка халыкларның сөйләм әдәбе кагыйдәләре белән чагыштыру, аларга характеристика бирү.

**Диктантларның күләме һәм аларны бәяләү**

- Диктант- укучының гомуми грамоталылыгын тикшерү өчен уздырыла торган язма эшнең бер төре. Диктантлар өйрәтү һәм контроль төрләргә бүленә.

**Өйрәтү диктантын бәяләү.**

- Өйрәтү диктантлары берничә төрле була: сүзлек диктанты, искәртмәле, аңлатмалы, сайланма, иҗади, күрмә, хәтер, ирекле диктантлар.

**Родная (татарская) литература (для татароязычных групп)**

5-9 нчысыйныфларда туган телдә әдәбият укытуның **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәбиятны мөстәкыйль укып, аңларлык күнекмәләр булдыру;
- татар сүз сәнгатен рус һәм дөнья әдәбияты фонында кабул итәргә өйрәтү;
- татар әдәби теле нормаларын саклап язу һәм сөйләү күнекмәләре булдыру;
- кирәкле мәгълүмат һәм белемнәрне төрле чыганаклардан табу, алардан мөстәкыйль рәвештә кулланырга өйрәтү.

Югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- татарча әдәби текстны кабул итәргә һәм аңларга, иҗат ителгән чор белән тарихи-мәдәни бәйләнешләрен һәм аңа салынган мәңгелек кыйммәтләрне күзалларга өйрәтү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен беркадәр билгели, геройларын бәяли алуына ирешү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларына кагылышлы төп фактларны белүенә ирешү;
- татар әдәбияты текстларын рус әдәбияты әсәрләре белән гомумкешелек кыйммәтләренә мөнәсәбәттә чагыштыру күнекмәләре формалаштыру;

*бәяләү өлкәсендә*:

- татар әдәбиятына хас рухи-әхлакый кыйммәтләрне, әдәби-эстетик үзенчәлекләрне аңларга өйрәтү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү;
- баланың үзаңын үстерү, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- татар әдәбияты үрнәкләренә үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

*коммуникатив яктан*:

- татар әдәбияты әсәрләрен аңлап укый һәм кабул итә алуга ирешү;
- әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру,әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку,өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерергә өйрәтү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары аша эзләү күнекмәсе булдыру;
- укучының мөстәкыйль, иҗади фикерләвен активлаштыру;
- әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча татар телендә иҗади эшләр башкарырга өйрәтү.

*эстетик яктан*:

- әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен һәм милли үзенчәлекләрен тою хисе формалаштыру;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

**2. Раздел 2.2.3. Татарский язык основной образовательной программы основного общего образования изложить в следующей редакции:**

**2.2.3. Родной (татарский) язык (для татарскоязычных групп)**

**5 КЛАСС**

**4 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау**

Лексикология буенча үткәннәрне кабатлау

Башлангыч сыйныфларда исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль буенча үткәннәрне кабатлау

Синтаксис буенча өйрәнгәннәрне кабатлау: сүзтезмә һәм җөмлә; җөмләнең баш кисәкләре; җәенке һәм җыйнак җөмләләр; җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергыч; җөмләнең тиңдәш кисәкләре. *Тикшерү характерындагы диктант язу,*

*Мәкаләне редакцияләү*

**Фонетика, орфоэпия, графика, орфография**

Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә

Сөйләм органнары. Авазларның ясалышы. Сөйләм аппараты

Татар телендә сузык һәм тартык авазлар
Татар телендә авазларның әйтелеше. Сингармонизм законы: рәт һәм ирен гармониясе
Тартык авазлар классификациясе. [къ] һәм [к], [гъ] һәм [г] тартык авазлары. [һ] һәм [х] тартык авазлары. [w] һәм [в] тартык авазлары
[н] һәм [ң] тартык авазлары. [’](һәмзә) тартыгы
Тартык авазларның сөйләмдәге үзгәреше. Тартыклар чиратлашуы. Борын ассимиляциясе. Ирен ассимиляциясе
Татар телендә иҗек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. Сүз басымы. Интонация
**Графика** һәм орфография. Аваз һәм хәреф төшенчәләре. Татар алфавиты
Сузык аваз хәрефләре. О, ө, е, э хәрефләренең дөрес язылышы
Тартык аваз хәрефләре. ь һәм ъ билгеләренең дөрес язылышы. В, к, г хәрефләре.
Сүзләрне кушып, сызыкча аша һәм аерым язу. Баш хәреф һәм юл хәрефләре
Сүзләргә фонетик анализ ясау
*Төрле характердагы диктантлар язу, изложение һәм сочинение язарга өйрәнү.*
**Лексикология**
Лексикология. Лексика һәм лексикология турында төшенчә. Сүзнең лексик мәгънәсе, аны аңлату юллары. Аңлатмалы сүзлекләр. Сүзләрнең мәгънәләре, килеп чыгышы һәм кулланылышы ягыннан төркемләү
Бер һәм күп мәгънәле сүзләр
Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре
Синоним. Антоним. Омоним
Килеп чыгышы буенча татар теленең сүзлек составы. Гомумтөрки һәм алынма сүзләр. Татар сүзләренең төркемнәре
Кулланылу өлкәсе буенча татар теленең сүзлек составы. Гомуми кулланылыштагы (гомумхалык сүзләре) һәм кулланылышы чикләнгән (диалекталь һәм һөнәрчелек сүзләре) сүзләр
Кулланылу активлыгы буенча сүзлек составы: искергән һәм тарихи сүзләр. Искергән сүзләр турында төшенчә
Яңа сүзләр (неологизмнар)
Фразеологизмнар. Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә куллану
Сүзләргә лексик анализ ясау
*Төрле характердагы диктантлар язу, изложение язарга өйрәнү, фразеологик әйтелмәләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү, “Сүз турында сүз” темасына фикер алышу, сүзлекләрдән файдалану.*
**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.**
Сүзнең тамыры һәм кушымчалар. Сүзнең мәгънәле кисәкләргә бүленеше
Мөнәсәбәт белдерә торган кушымчалар: модальлек һәм бәйләгеч кушымчалар
Модальлек кушымчалары. Исем, сан, сыйфат, фигыльләргә ялгана торган модальлек кушымчалары
Сүзнең нигезе. Тамыр һәм ясалма нигезле сүзләр
Сүзләрнең төзелеше буенча тикшерү
Сүз ясалу ысуллары. Ясагыч кушымча ялгау ысулы. Сүзгә кушымчалар ялгану тәртибе
Сүзләрне кушу ысулы: кушма, парлы, һәм тезмә сүзләр ясалу
Сүзләрне кыскарту ысулы
*Изложение язарга өйрәнү, картина буенча сочинение язу (И.Шишкин. “Имәнлек”), сүзлекләрдән файдалану*
**5нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау.**
Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау
*Изложение язарга өйрәнү, текстларны бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү.*

**6 КЛАСС**

**5 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау.**
Сузык һәм тартык авазлар; татар һәм рус телләренең икесендә дә булган, әмма әйтелеше белән татар телендә аерылып торган авазлар; татар теленең үзенчәлекле авазлары; татар телендә иҗек калыплары; сүзләрнең басымын билгеләү; сүзләргә фонетик анализ ясау.

Сүзнең лексик мәгънәсе; килеп чыгышы һәм кулланылу өлкәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Сүзлекләр турында белешмә. Аларның төрләре. Сүзлекләрнең төзелү принциплары. Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.
Татар һәм рус телләрендә тамыр һәм кушымчаларның үзенчәлекләрен искә төшерү. Бәйләгеч һәм модаль кушымчалар, аларның сүзгә ялгану тәртибе. Сүзнең нигезе, тамыры. Татар телендә сүз ясалу ысуллары. Сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерү.

**Морфология.**

Сүз төркемнәре турында гомуми мәгълүмат бирү.

**Исем.**

Исем турында төшенчә. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше.Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.
Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Алынма сүзләрдәге килеш һәм тартым кушымчалары. Исемнәрнең ясалышы. Исемнәргә морфологик анализ ясау.
*Тәрҗемә итү күнегүләре, төрле типтагы диктантлар, изложение,сочинение.*

**Сыйфат.**

Сыйфат турында төшенчә. Сыйфатларның ясалышы. Сыйфат дәрәҗәләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфатның исемләшүе. Сыйфатларны сөйләмдә куллану. Сыйфатларга морфологик анализ ясау.
*Хикәя язу, аңлатмалы диктант.*

**Сан.**

Сан турында төшенчә. Саннарның исемләшүе. Саннарның ясалышы. Гарәп һәм рим цифрларының язылышы. Сан төркемчәләре. Микъдар саны. Тәртип саны. Чама саны. Бүлем саны. Җыю саны. Саннарның җөмләдә кулланылышы.Саннарга морфологик анализ ясау.
*Диктант язу.*

**Рәвеш.**

Рәвеш турында гомуми мәгълүмат. Аның лексик-грамматик мәгънәсе һәм морфологик үзенчәлекләре.Рәвешләрнең ясалышы.Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре. Саф рәвешләр. Охшату-чагыштыру рәвешләре.Күләм-чама рәвешләре. Урын рәвешләре. Вакыт рәвешләре. Сәбәп-максат рәвешләре.Рәвешләрнең сөйләмдәге роле.Рәвешләргә морфологик анализ ясау.
*Изложение, диктант.*

**Алмашлык.**

Алмашлык турында төшенчә. Алмашлыкларның ясалышы. Зат алмашлыклары. Тартым алмашлыклары. Күрсәтү алмашлыклары. Сорау алмашлыклары. Билгеләү алмашлыклары. Билгесезлек алмашлыклары. Юклык алмашлыклары. Алмашлыкларга морфологик анализ ясау.
*Сайланма диктант, тәрҗемә итү күнегүләре.*

**Фигыль.**

Фигыль турында төшенчә. Татар телендә фигыльнең нигезе (башлангыч формасы) турында гомуми мәгълүмат. Фигыльнең барлык – юклык формалары. Фигыльләрнең ясалышы. Затланышлы фигыльләр. Боерык фигыль, аның мәгънәләре, зат – сан белән төрләнеше. Боерык фигыльнең дөрес интонация һәм басым белән кулланылышы. Хәзерге заман хикәя фигыль, аның мәгънәләре, формалары, зат – сан белән төрләнеше. Үткән заман хикәя фигыль, аның мәгънәләре, формалары, зат – сан белән төрләнеше. Киләчәк заман хикәя фигыль, аның мәгънәләре, формалары, зат – сан белән төрләнеше. Шарт фигыль, аның мәгънәләре, формалары, зат – сан белән төрләнеше.

**6нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау.**

Исем, исемнәрнең килеш,сан,тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең ясалышы. Исемнәрнең морфологик билгеләре. Сүз төркеме - сыйфат. Сыйфатларның ясалышы, төркемчәләре. Сыйфатларның дәрәҗәләре. Сыйфатларның җөмлә төзүдәге роле. Сүз төркеме – сан. Аларның ясалышы һәм төркемчәләре. Саннарның сөйләмдәге кулланылышы. Сүз төркеме – рәвеш. Төрләнми торган сүз төркеме – рәвешнең ясалышы, төркемчәләре. Алмашлыклар. Аларның ясалышы. Төркемчәләре. Алмашлыкларга морфологик анализ ясау.Алмашлыкларның сөйләм төзүдәге роле,кулланылышы.
*Изложение,сочинение,йомгаклау контроль эш (диктант).*

**7 КЛАСС**

**6 нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау.**

Фонетика. Сүз төркемнәре. Исем, сан, рәвеш, алмашлык, сыйфат сүз төркемнәрен кабатлау.

**Сүз төркемнәре.**

**Фигыль.**

Фигыль сүз төркеме. Фигыльләрнең ясалышы. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр. Сыйфат фигыль, сыйфат фигыльнең сыйфат һәм фигыль белән уртак яклары, үткән заман сыйфат фигыль, киләчәк заман сыйфат фигыль; хәл фигыль, хәл фигыльнең төрләре, хәл фигыльнең фигыльнең җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы;исем фигыль, исем фигыльнең исем һәм фигыль белән уртак яклары, исем фигыльнең исемгә әйләнү очраклары; инфинитив; ярдәмче фигыльләр, мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе, фигыль ясагыч кушымчалар. Фигыльләргә морфологик анализ ясау.

**Аваз ияртемнәре**.

Аваз ияртемнәре турында төшенчә. Аларның ясалуы, морфологик – синтаксик үзенчәлекләре. Аваз ияртемнәре нигезендә сүзләр ясалышы. Аваз ияртемнәренә морфологик анализ ясау.

**Хәбәрлек сүзләр.**

Хәбәрлек сүзләр турында төшенчә. Татар телендә хәбәрлек сүзләрнең тоткан урыны. Аларның формалары һәм җөмләдә кулланылышы. Хәбәрлек сүзләргә морфологик анлиз ясау.

**Бәйлекләр.**

Бәйлекләр турында гомуми мәгълүмат, Аларның сөйләмдә кулланылышы. Бәйлек төркемчәләре. Бәйлек сүзләр, аларның формалары, сөйләмдә кулланылышы. Бәйлекләргә морфологик анализ ясау.

**Теркәгечләр.**

Теркәгечләр турында гомуми мәгълүмат бирү. Теркәгечләрнең куллану үзенчәлекләре, аларның интонациягә бәйле булуы. Теркәгечләрне төркемләү. Теркәгеч сүзләр. Аларның формасы, теркәгечләрдән аермасы. Рус һәм татар телендә теркәгечләрнең уртак яклары. Теркәгечләргә морфологик анализ ясау.

**Кисәкчәләр.**

Кисәкчәләр турында гомуми мәгълүмат. Аларны мәгънәләре буенча төркемләү. Татар телендә кисәкчәләрнең дөрес язылышы. Кисәкчәләргә морфологик анлиз ясау.

**Ымлыклар.**

Ымлыклар турында гомуми мәгълүмат. Аларның ясалу үзенчәлекләре һәм сөйләмдә кулланылышы. Ымлыкларны төркемләү.

**Модаль сүзләр.**

Модаль сүзләр турында гомуми мәгълүмат, аларның кулланылышы.

**Морфология буенча үткәннәрне кабатлау.**

Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәре буенча алган белемнәрне кабатлау, ныгыту, морфологик анализ ясау һәм сөйләмдә урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү.

**8 КЛАСС**

**5-7нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау .**

Сүз ясалышы. Сүз төзелеше. Сүз төркемнәре. Фигыль сүз төркеме. Җөмләдә сүзләр тәртибе.Сүзләргә фонетик, лексик, морфологик анализлар ясау

*Грамматик биремле диктант язу“Өегез ямьле булсын” .*

**Синтаксис. Сүз һәм җөмлә.**

Синтаксис. Гади җөмлә синтаксисы һәм пунктуация. Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат. Телебезнең синтаксик һәм сөйләм берәмлекләре (сүз, сүзтезмә, җөмлә кисәкләре, җөмлә һәм текст) турында төшенчә . *“ Җитәкче батыр да булырга тиеш” дигән темага изложение язу.*

**Җөмләдә сүзләр бәйләнеше.**

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше турында гомуми мәгълүмат. Тезүле бәйләнеш. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. Аларны үзара теркәүче чаралар. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр. Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре. Ияртүле бәйләнешнең сөйләм оештырудагы роле. Сүзтезмә турында гомуми төшенчә. Сүзтезмәдә ияртүче һәм ияртүче кисәкләр. Татар телендә сүзтезмәләрнең төрләре һәм үзенчәлекләре. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен кабатлау.*Картина буенча сочинение,”Җиңәсем килде” дигән темага изложение, грамматик биремле “Күзләрегезне саклагыз” дигән диктант язу*.

**Җөмлә кисәкләре.**

Җөмлә кисәкләре турында гомуми мәгълүмат (башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү).

**Җөмләнең баш кисәкләре**

Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм аның белдерелүе, төрләре. Хәбәр һәм аның белдерелүе, төрләре. Ия белән хәбәрнең җөмләдәге урыны. Ия белән хәбәр арасына сызык кую очраклары “Минем яраткан шөгылем” дигән темага *сочинение язу, тәрҗемә күнегүләре эшләү.*

**Гади һәм кушма җөмлә.**

Гади һәм кушма җөмлә турында гомуми мәгълүмат.*Татар һәм рус телләрендә кушма җөмләләрне чагыштыру.*

**Җөмләнең иярчен кисәкләре**

Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч һәм аның белдерелүе һәм аерылмыш белән бәйләнеше. Тиңдәш һәм тиңдәш түгел аергычлар. Тәмамлык һәм аның белдерелүе. Туры һәм кыек тәмамлыклар. Хәл һәм аның төрләре. Урын хәле. Вакыт хәле. Рәвеш хәле. Күләм хәле. Сәбәп хәле. Максат хәле. Шарт хәле. Кире хәл. Төрле хәлләрнең аерымлануы һәм алар янында тыныш билгеләре. Аныклагыч турында гомуми мәгълүмат. Аныклагычның аныкланмыш белән бәйләнеше. Аныклагычларның аерымлануы һәм алар янында тыныш билгеләре. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен гомумиләштереп кабатлау. *Тормышта үрнәк булырдай берәр кеше турында очерк язу, әдәби геройларга характеристика.бирү, “Матурлык”, “Китап- белем чишмәсе”дигән темаларга сочинениеләр язу, грамматик биремле төрле характердагы диктантлар,”Сихерле чәчәкләр” дип исемләнгән изложение язу.*

**Җөмләнең модаль кисәкләре.**

Модаль кисәкләр. Эндәш сүзләр, аларны куллану үзенчәлекләре. Эндәш сүзләрнең җөмләдәге урыны, алар янында тыныш билгеләре. Кереш сүзләр , аларны мәгънә ягыннан төркемләү. Кереш сүзләр янында тыныш билгеләре *Сүзлек диктанты, “Актәпи” исемле изложение язу.*

**Грамматик анализ төрләре.**

Грамматик анализ турында гомуми төшенчә.(алдагы сыйныфта өйрәнгәннәргә нигезләнү) Морфологик, синтаксик, морфологик-синтаксик, синтаксик-морфологик анализ төрләре.

**Җөмләнең баш, иярчен, модаль кисәкләрен кабатлау.**

Җөмләнең баш, иярчен, модаль кисәкләре. Алар янында тыныш билгеләре. Грамматик анализ төрләре. *Әдәби әсәр героена хат язу, “грамматик биремле диктант язу*

**Гади җөмләләрне төркемләү. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре.**

Гади җөмләләрне төркемләү. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре: хикәя җөмлә, сорау җөмлә, боеру җөмлә һәм тойгылы җөмләләр. Әйтү максаты ягыннан төрле җөмләләр янында куела торган тыныш билгеләре *“Урман чисталыгы” дигән темагасочинение язу.*

**Раслау һәм инкяр җөмләләр.**

Раслау һәм инкяр җөмләләр турында гомуми төшенчә һәм аларның кулланылышы. Инкяр җөмләләрне белдерүче чаралар.

**Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.**

Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында гомуми төшенчә (башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү*). ”Артыш” дип исемләнгән грамматик биремле диктант язу.*

**Ике составлы һәм бер составлы җөмләләр.**

Бер составлы җөмлә төрләре һәм аларның үзенчәлекләре.Бер составлы исем җөмлә. Бер составлы фигыль җөмлә. *“Соры мәче” дип аталганизложение язу.*

**Тулы һәм ким җөмләләр.**

Тиешле җөмлә кисәгенең кулланылу-кулланылмавына карап, җөмлә төрләре: тулы һәм ким җөмләләр. Аларны куллану үзенчәлекләре *Сүзлек диктанты, текст буенча сочинение язу.*

**Җөмлә төрләрен кабатлау**

Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен, раслау һәм инкяр,җыйнак һәм җәенке, ике һәм бер составлы, тулы һәм ким җөмләләрне куллану үзенчәлекләре *Тест биремнәрен үтәү.*

**8нче сыйныфта өйрәнгәннәрне кабатлау.**

Гади җөмлә синтаксисы. Гади җөмләләрне төркемләү.Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең баш, иярчен, модаль, тиңдәш һәм аерымланган кисәкләре. Грамматик анализ төрләре. Алар янында тыныш билгеләре *Проект-тикшерү эше башкару, “Тукай маршы” дип аталгн грамматик биремле диктант язу.*

**9 КЛАСС**

**Синтаксис буенча өйрәнгәннәрне искә төшерү.**

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше, аларны белдерүче грамматик чаралар. Сүзтезмәләр, аларның төрләре, җөмләләрне сүзтезмәләргә таркату.

**Кушма җөмлә синтаксисы һәм пунктуация.**

Кушма җөмлә турында төшенчә. Тезмә кушма җөмләләр, аларның төрләре. Алар янында тыныш билгеләре. Иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. Баш һәм иярчен җөмлә. Баш җөмләнең иярчен җөмләгә бәйләнү ысуллары.Аналитик һәм синтетик җөмләләр турында төшенчә. Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар һәм алар янында тыныш билгеләре. Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар һәм алар янында тыныш билгеләре. Мәгънәсе ягыннан иярчен җөмләләрнең төрләре. Аларның төп үзенчәлекләре, бәйләүче чаралар. Алар янында тыныш билгеләре.
Катлаулы кушма җөмләләр турында төшенчә. Тиңдәш иярүле, тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмләләр. Аларның ясалу үзенчәлекләре. Алар янында тыныш билгеләре. Катлаулы кушма җөмләләр. Катнаш кушма җөмләләр. Аларның схемалары. Бу җөмләләргә синтаксик анализ ясау.

**Текст синтаксисы һәм пунктуация.**

Текст синтаксисы турында гомуми төшенчә. Тезем.Чит сөйләмле текст. Тезем янында куела торган тыныш билгеләре.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы**

Әдәби тел һәм аның стильләре. Язма һәм сөйләмә стильләр турында төшенчә. Матур әдәбият стиле. Фәнни һәм рәсми стильләр. Эш кәгазьләре стиле. Эпистоляр һәм рәсми стильләрнең үзенчәлекләре.
Стильләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләре. Сөйләм культурасы. Сөйләм төгәллеге турында төшенчә. Лексик һәм грамматик калькалар турында төшенчә.

**5-9 нчы сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.**

Фонетика, орфография,графика буенча алган белемнәрне искә төшерү. Сүз ясалышы һәм сүз төзелешен ныгыту. Морфология һәм синтаксис буенча алган белемнәрне актуальләштерү.Синтаксик анализ ясауны ныгыту.

**3. Раздел 2.2.4. Татарская литература основной образовательной программы основного общего образования изложить в следующей редакции:**

**2.2.3. Родная (татарская) литература (для татарскоязычных групп)**

**5 КЛАСС**

**Кереш.**

И.Газинең китап турында “Үзе бер могҗиза” язмасын укып фикер алышу. Дәреслекнең төзелеше. Китап турында мәкаль, табышмак, кызыклы мәгълүматлар.

**Халык авыз иҗаты турында (фольклор).** Бишек җырлары тыңлау.

**Әдәбият теориясе**. Халык авыз иҗаты турында (фольклор).

**Татар халык әкиятләре.**

Тылсымлы әкият һәм аның геройлары “Ак байтал” әкияте. Ат турында мәкальләр. Атка мәдхия. БСҮ темасы: “Татар халкы ат ярата”
Көнкүреш әкиятләре ”Үги кыз”.
Хайваннар турында әкиятләр “Хәйләкәр төлке ”.
“Солдат балтасы”, “Өч каләм”, “Камыр батыр”, “Кәтән Иваныч” әкиятләренең кайсы төргә керүләрен һәм нинди билгеләре буенча төркемләнүләрен ачыклау.

**Әдәбият теориясе.** Әкият. Әкият төрләре. Әкият төзелеше. Даими эпитетлар. Гипербола турында төшенчә. Чагыштырулар, кабатлаулар.
Мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмаклар.
Мәзәкләр.
Мәсәлләр. Г. Тукай мәсәлләре.
И.Крылов мәсәлләре.

**Борынгы, урта гасырлар татар әдәбияты.**

Кол Гали. “Кыйссаи Йосыф” әсәре.

***Казан ханлыгы әдәбияты***.Мөхәммәдьяр иҗаты

**XIX йөз әдәбияты.**

Каюм Насыйриның биографиясе һәм иҗаты.
К. Насыйри “Патша белән карт”

**XX гасыр татар әдәбияты**

Г. Тукай – татар халкының бөек шагыйре.

Г.Тукай ”Су анасы” әкият-поэмасы.
***Совет әдәбияты.***
Г. Ибраһимовның биографиясе һәм иҗаты. Г. Ибраһимовның” Яз башы” әсәре.
М. Җәлилнең биографиясе һәм иҗаты.
Муса Җәлил. “Алтынчәч” либреттосыннан өзек
***Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты.***
М. Җәлил. “Кызыл ромашка” , “Җырларым” шигырьләре.
“Хөкем алдыннан” картинасы буенча сочинение.
Ф. Кәрим шигырьләре. “Кыр казы”.
“Ватаным өчен” шигырьләре.
А. Алишның тормыш юлы һәм иҗаты. “Килделәр” хикәясе.
С. Хәким “Колын” шигыре.
***Сугыштан соңгы чор әдәбияты***
Ф. Хөсни. “Чыбыркы” хикәясе.
Н. Дәүли “Бәхет кайда була?” шигыре, “Кар нинди җылы...” хикәясе.
Ф. Яруллин. “Зәңгәр күлдә Ай коена” әкияте.
**Туган ил, туган як.**
Н. Исәнбәт. “Туган ил” шигыре.
Н. Мадъяров. “Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигыре.
С.Хәким. “Бер горурлык хисе”, “Башка берни дә кирәкми” шигырьләре
М. Әгъләмов. “Матурлык минем белән” шигыре.
Туган як турында шагыйрьләр. Шишкин наратлары.
**Тәрҗемә әсәрләр.**
А Платонов “Ягъфәр бабай”.
Д. Родари. “Әбинең кошчыклары”.
**Язучылар иҗатында юмор.**
Алмаз Гыймадиев ”Телефонлы кәҗә”, ”Интернетта-ALF!”.
Л.Лерон. “Зөһрә кыз –безнең авылдан”, “Песи булсаң иде” хикәяләре.
Р.Миңнуллин ”Уйлап табучы”, ”Әгәр мин икәү булсам”.

**6 КЛАСС**

**Дәресләрдә кулланышта булган теоретик материал:**
Лирик герой, хикәяләүче герой, рифмадаш сүз, рифма төрләре, сюжет, пейзаж, юмор, сатира, портрет, строфа, бәет строфасы, метафора, сынландыру, эпитет, сүз уйнату, ирония турында төшенчә, инверсия, афоризм, повесть, баллада, бәет, кече эпик жанр, мәкаль, чагыштыру, балет, либретто, җыр төрләре, хикәя, прототип, хикәяләүче образы.

**Төп эчтәлекнең темаларга бүленеше**

**Халык авыз иҗаты**
Халык җырлары. Җырларның туу тарихы. Халык җырлары турында әдипләр фикере.
Фәнис Яруллин. «Җыр» шигыре. Шагыйрьнең җырларга биргән бәяләмәсе. Җыр турында татар галимнәре — И. Надиров, К. Миңнуллин фикере.
«Кил, өйрән...» шигыре. «Кил, өйрән...» шигыренә бәйләп телләр белүнең әһәмияте турында сөйләшү
**Балачак — хәтерләрдә мәңге калачак...**
Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәреннән өзек. Әсәрдә кечкенә Тукай образының бирелүе. Автобиографик әсәр герое белән Тукай арасында уртак һәм аермалы яклар. Кечкенә Габдулланың Хаҗиморат Казаковның «Бәләкәй Апуш» картинасында сурәтләнеше
Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее. Музей урнашкан төбәк. Андагы истәлекле экспонатлар.
Теоретик мәгълүмат. Мемориаль комплекс.
«Салават күпере» журналы. Аның тарихы һәм бүгенгесе турында мәгълүмат
**Ватаным өчен.**
Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» повестеннан «Әби әкияте», «Яз җиткәч», «Сихерле чәчәкләр», «Расад» бүлекләрен уку. Рөстәм образы турында сөйләшү. Малайга хас сыйфатларны табу. Хыял белән чынбарлык арасындагы аерманы табарга өйрәнү
Муса Җәлил.
«Сагыну», «Соңгы җыр» шигырьләре. Аларга салынган хисне аңлау.
«Алтынчәч»либреттосыннан өзек өйрәнү. Либреттоның әкияткә һәм дастанга нигезләнеп
300
язылган булуы. Аның төп каһарманнары: Тугзак ана, Җик, Алтынчәч. Нәҗип Җиһановның либреттога музыка язуы. Композиторның иҗаты.
Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры турында мәгълүмат
Фатих Кәримнең «Кыр казы», «Ватаным өчен», «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» шигырьләрен уку. Аларда Туган илне саклау, ярату хисләренең салынган булуы
Лев Кассильнең «Мәңгелек хәтер». Мәскәү Кремле янындагы мәңгелек ут.1965 нче елда Мәскәүгә герой-шәһәр исеме бирелүе.
Шәүкәт Галиевның «Аталы-уллы солдатлар» балладасы. Илне басып алучыларга көрәштә халыкның фидәкарьлеге. Ил батырларына хөрмәт.
**Кояшлы ил – бәхет иле.**
Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» «Мин җирдә калам» шигырьләрендә бәхет эзләү һәм табу кебек фәлсәфи мәсьәләнең чишелеше. Лирик герой өчен бәхетнең үзе яшәгән җирдә булуы.
Теоретик төшенчә.Шигырь. Ритм. Рифма
Фатих Хөсни. Автор турында белешмә.
«Чыбыркы» хикәясе. Хикәядә малайның үз эшләре өчен җавап бирүе. Авторның бала психологиясен ачу үзенчәлеге.
Әдәбият теориясе. Сюжет. Сюжет элементлары (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш)
Фоат Садриевның «Көнбагыш чәчәге» хикәясе. Яхшылыкның нәтиҗәсе яхшылык булуын аңлау.
Әхмәт Рәшитовның « Кояшлы ил – бәхет иле» шигыре. Туган ил кадерен белергә өйрәтү. Лирик геройның кичерешләрен ачу.
Мәгъсүм Хуҗинның «Туган көн» хикәясе. Олыларга игътибарлы булырга өйрәтү. Кешеләрнең күңелен күтәрү – зур бәхет булуын ачыклау.
**Кеше – табигать баласы.**
Равил Фәйзуллинның «Табигать кочагында» шигыре. Шигырьдә табигатьне саклау, аны ярату хисләре өстенлек итүен ачыклау
Мөдәррис Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигыре, «Җир-ана, кояш һәм башкалар» балладасы. Матурлыкны табигатьтән эзләү мотивы. Табигатьнең кешеләргә

мәрхәмәтле булуы, аны сакларга кирәклеге
Рәссам Иван Иванович Шишкин иҗаты. Аның Татарстан белән бәйле язмышы.
Иҗаты
Гәбделхәй Сабитовның «Чәчәк нигә боекты?» хикәясе. Кызчыкның әнисенә ярдәм
итүе, табигатьне яратуы.
Борис Вайнерның «Искиткеч китап». Елның дүрт фасылы. Аларның һәрберсе
үзенчә матур булуы.
**Эш беткәч көләргә ярый.**
Ләбиб Леронның «Пирамида» хикәясе. Укучыларда белем алуга теләк тудыру.
Укымыйча гына белемле булып булмавын ачыклау.
Алмаз Гыймадиевның «Зөлфия + ... мин» хикәясе. Яшүсмерләрне беренче
мәхәббәт хисләренең сурәтләнеше. Язуда гына түгел, тормышта да хаталар җибәрергә
ярамавын ачыклау
Шәүкәт Галиевның «Әлләкем» шигыре. Шагыйрьнең табышмак, юмористик
шигырьләрендә бала хисләренең ачылышы.

**6 КЛАСС**

**Мифлардан чынбарлыкка.**
Фольклор – халыкның коллектив иҗат җимеше. Анда халыкның теләк-омтылышының чагылышы. Фольклорның вариантлы булуы. Фольклор әсәрләренең жанрларын гомуми күзаллау. Балалар фольклоры (бишек җырлары, табышмаклар, тизәйткечләр, мәкальләр һ.б.). Башка халык авыз иҗаты белән чагыштыру.
Әдәбият теориясе. Фольклор. Халык авыз иҗаты
**Мифлар.**
Мифлар – кешеләрнең дөньяны фантастик аңлавы. Мифик геройлар турында
төшенчә. Миф белән әкиятнең аермасы. Рус, грек мифлары белән чагыштыру. «Шүрәле», «Шүрәлене ничек алдарга?» мифы. Мифларны өйрәнгән галимнәр. Язучылар иҗатында мифик геройлар. Рабит Батулланың “Албасты” пьесасы.
Әдәбият теориясе. Миф.Мифик геройлар
**Мәкальләр һәм әйтемнәр.**
Мәкальнең акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен кулланылуы. Мәкальләрнең
тематикасы. Әйтемнең күчерелмә мәгънәдә кулланылган, сөйләмнең эмоциональ көчен
арттыра торган жанр булуы. Мәкаль белән әйтемнең аермасы. Татар мәкальләре һәм
әйтемнәренең русча эквивалентлары.
Әдәбият теориясе. Мәкаль, әйтем
**Халык моңнары: җырлата да, елата да...**
**Халык җырлары.**
Халык җырларының авторы халык булуы. Аларның вариантлылыгы. Халык
җырларының жанрлары. Йола җырлары, аларның килеп чыгу үзенчәлеге. Йола
бәйрәмнәреннән Сөмбелә бәйрәме. Чуваш халык бәйрәме Чуклеме. Уен җырлары. “Кәрия-Зәкәрия” җыры.
Әдәбият теориясе. Халык җырлары. Халык җыры жанрлары. Йолалар, йола
җырлары. Тарихи җырлар. Уен җырлары
Шигърияттә халык көе. Шагыйрьләрнең кайбер шигырьләре халык тарафыннан көйгә салынуы.
Г.Тукайның “Туган тел” шигыре. Аның төрле телләргә тәрҗемә ителүе.
Г.Тукайның “Туган авыл” шигыре. Аның дә халык җыры кебек яратып җырлануы,
киң таралган булуы. Композитор А.Монасыйпов турында кыскача белешмә. Кешенең
балачагы үткән туган якның кадере.
Әдәбият теориясе. Автор җырлары
Татарстан Республикасы гимны.
Гимнның дәүләт символы булуы. Гимн уйнала торган очраклар. Гимнны тыңлау
тәртибе. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторлары Р.Байтимеров, Р.Яхин. Гимн текстының эчтәлеге, көе.
Әдәбият теориясе. Гимн
Җырны башкаручы – җырчы.
Җырның яшәвендә башкаручының роле. Җырчы Р. Ваһапов – милли профессиональ
эстрадага нигез салучы.

Әдәбият теориясе. Профессиональ җырчы
**Кадерле син, кеше-туганым!**
Нәкый Исәнбәт. Язучы турында кыскача белешмә.
“Өч матур сүз” шигыре. Әти-әни, туган илнең кадере. Шигырьдәге лирик герой.
Шигырьнең диалог формасында язылуы. Шигырьнең Г.Тукайның “Туган тел” шигыре белән аваздашлыгы.
Әдәбият теориясе. Лирик герой. Сынландыру.
Мәҗит Гафури. Әдип турында кыскача белешмә. Рус мәсәлчеләре белән чагыштырып өйрәнү.
«Әтәч белән Сандугач» мәсәле. Мәсәлдә туган җир кадере темасының дәвам итүе.
Ирек, кеше өчен ирек кадере турында белешмә. Мәсәлдә сынландыру алымы. Мәсәлнең морале.
“Ана” шигыре. Шигырьдә ана өчен бала, бала өчен ана кадере. Н.Исәнбәт шигырьләре белән аваздашлыгы. Бишек җырларының әһәмияте турында мәгълүмат.
Әдәбият теориясе. Мәсәл
Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат.
“Шүрәле” әкият-поэмасы. Әкият-поэмада кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, туган авыл табигатенең матурлыгы. Шүрәле мифик образы. Әсәрдә егет һәм Шүрәле образларының бирелеше, аларга салынган мәгънә. Г.Тукай әкиятләренә иллюстрацияләр авторы – Байназар Әлменов
Фәрит Яруллин. Композитор турында белешмә.
“Шүрәле” балеты. Г.Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасына балет язылу. Балет авторлары Ф.Яруллин, Ә.Фәйзи, Л.Якобсон турында мәгълүмат. Былтыр, Шүрәле образларының бирелеше. Сөембикә образы, аңа салынган мәгънә.
Әдәбият теориясе. Балет
Муса Җәлил. Шагыйрьнең тормыш юлы, сугыш чоры иҗаты, “Моабит дәфтәрләре” турында мәгълүмат. М.Җәлилнең музей-квартирасы.
“Чәчәкләр” шигыре. Шигырьнең язылу урыны, вакыты. Шигырьдәге символлар.
Ччәкләрнең матурлык һәм үлемсезлек символы буларак бирелүе. Туган илне ярату, туган илне саклау идеясе.
Әдәбият теориясе. Символ, строфа
Әмирхан Еники. Әдип турында кыскача белешмә.
“Туган туфрак” хикәясе. Әсәрнең төп идеясе. “Нигез”, “Туган туфрак” төшенчәләре. Авыл табигатенең, авыл халкының бирелеше. Хикәядәге символлар. Клараның эчке кичерешләре. Авыл проблемалары
**Энҗе карлар явып үткән...**
Галимҗан Ибраһимов. Әдип турында кыскача белешмә.
“Кар ява” хикәясе. Кышкы табигать, кар яву күренешенең тасвирлануы. Хикәядә чагыштырулар
Кави Нәҗми. Шагыйрь турында кыскача белешмә.
“Кызыклы хәл” шигыре. Шигырьдә Вилдан белән булган хәлнең бирелеше. Строфа, рифмалар. Эчтәлекне ике өлешкә бүлеп карау мөмкинлеге. Шигырьдәге юмор
Мәрзия Фәйзуллина. Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә.
“Чыршының күлмәкләре” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы.
Чагыштырулар, сынландыру. Шигырьдә күтәрелгән экология проблемасы
Резеда Вәлиева. Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат.
“Нәни чыршы” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, кулланылган троплар. Шигырьдә күтәрелгән проблема
Туфан Миңнуллин. Тормыш юлы турында мәгълүмат (5 сыйныфта үткәннәргә өстәмә).
“Акбай һәм Кыш бабай” пьесасы. Пьесада Яңа ел бәйрәменә әзерлекнең бирелеше.
Кыш бабай белән Кар кызы теләкләре. Яңа ел белән котлау сүзләре
**Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое.**
Каюм Насыйри. Әдип турында кыскача белешмә. Аның энциклопедист галим булуы.
Казандагы һәм Яшел Үзән районындагы музейлары.
“Әбүгалисина” кыйссасы. Әбүгалисина һәм Әбелхарис образлары. Аларның

белемгә омтылышлары, белем өйрәнүдәге тырышлыклары. Белемнең файдасы. Әбүгалисинаның ярлы егеткә, Әбелхарисның патшага булышуы. Туганлык һәм көнчелек хисләре. Әбүгалисинаның галим булып танылуы.
Әдәбият теориясе. Кыйсса
Габделхәй Сабитов. Язучы турында кыскача белешмә.
“Чүкеч” хикәясе. Язучының әйтергә теләгән фикере. Хикәядә малай һәм ата образлары. Әсәрдә искә алынган эш кораллары.
Әдәбият теориясе. Хикәяләү
Абдулла Алиш. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.
“Әни ялга киткәч” хикәясе. Хикәянең төп идеясе. Малайның яңага омтылышы, эшчәнлеге. Малайның өйдә башкарган эшләре. Малайның эшкә өйрәнүе турындагы мәкальләр.
Әдәбият теориясе. Хикәяләүче
Фәнис Яруллин. Әдип турында кыскача белешмә.
“Кояштагы тап” хикәясе. Әсәрнең төп идеясе. Малай һәм ана образлары. Хикәядә ялганның, ялкаулыкның фаш ителүе. Яманлыкның эзе калуы.
Әдәбият теориясе. Притча
Гөлшат Зәйнашева. Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат.
“Кем булырга?” шигыре. Шагыйрәнең әйтергә теләгән фикере. Шигырьдә әйтелгән һөнәрләр. Һөнәр сайлауның мөһимлеге.
Мәгъсүм Латыйфуллин. Язучы турында кыскача белешмә.
“Сәйдәшнең юл башы” хикәясе. Салих Сәйдәшевның һөнәр сайлавында зур роль уйнаган вакыйга. Танылган кешеләрнең төрле һөнәрләр турында уйланулары. С.Сәйдәшевның тормышына йогынты ясаган шәхесләр.
Әдәбият теориясе. Биографик әсәр
Салих Сәйдәшев. Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә.
С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы, музее, һәйкәле
Равил Фәйзуллин. Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат.
“Бердәнбер” шигыре. Шигырьнең төп идеясе. Бердәнбер сүзенең мәгънәсе. Шигырьнең төзелеше
**Ил өстендә илле дустың булсын.**
Дәрдемәнд. Әдип турында кыскача белешмә.
“Ике туган” хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Туганлык мөнәсәбәтләренең бирелеше. Әтәч белән тавыкның кешеләштереп (персонификация) бирелүе. Сәламәт булуның, куркынычсызлыкның элементар кагыйдәләре
Һади Такташ. Шагыйрь, аның балачагы турында мәгълүмат.
“Мокамай” поэмасы. Поэманың эчтәлеге. Мокамай образының прототибы. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Тормыштагы ялгыш адымның һәлакәткә илтүе. Шагыйрьнең дуслык хисләренә тугрылыгы. Поэмадагы символлар.
Әдәбият теориясе. Поэма
Ренат Харис. Әдип турында кыскача белешмә. Аның төрле яклы иҗаты.
“Серле алан” пьесасы. Пьесаның эчтәлеге. Малайлар, карт образлары. Пьесадагы символик образлар. Ваемсызлык нәтиҗәләре. Бәхет, тынычлык өчен һәр кешенең җавалылыгы.
Әдәбият теориясе. Символик образ. Диалог. Монолог
Эльмира Шәрифуллина. Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат.
“Дуслык, чын дуслык!” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, төзелеше. Дуслыкның көче турында уйлану
Шәүкәт Галиев. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.
“Дуслык балы” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге. Шигырьдә күтәрелгән милләтара дуслык, толерантлык проблемалары.
Шигырьнең строфалары, рифмалары, троплар
**Көлке көлә килә...**
Шәүкәт Галиев. “Курыкма, тимим”, “Атлап чыктым Иделне” шигырьләре. Шигырьләрнең эчтәлекләре. Һәр шигырьдәге юмор
Фаил Шәфигуллин. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.

“Ике тиен акча” хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Марат образы. Хикәядәге юмор.
Язучының юмор аша әйтергә теләгән фикере. “Акбай белән Карабай” хикәясе.

**Һәр фасылың гүзәл, табигать!**

Роберт Әхмәтҗанов. Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат.
“Иртә әле...” шигыре. Шигырьдә табигать тасвиры. Кулланылган әдәби алымнар.
Туган ил кадере.
Әдәбият теориясе. Пейзаж
Гәрәй Рәхим. Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат.
“Апрель” хикәясе. Әсәрнең эчтәлеге. Төп идеясе. Хикәядәге чагыштырулар. Автор игътибарны юнәлткән табигать кануны.
Әдәбият теориясе. Портрет
Гомәр Бәширов. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.
“Туган ягым – яшел бишек” повестеннән өзек. Сабантуй турындагы өзекнең эчтәлеге. Сабантуй бәйрәменең тасвирлап бирелеше. Көрәшче егетләр, Хәкимҗан образлары. Сурәтләү чаралары. Сабантуй бәйрәме тарихы.
Лотфулла Фәттахов.
Рәссамның тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Сабантуй” картинасында сурәтләнгән табигать, авыл кешеләре.
Б.Рәхмәт “Сабан туенда” шигыре.
Балалар өчен чыга торган газета-журналлар.
“Сабантуй” журналы. Журнал басылып чыгу тарихы. Журнал рубрикалары.
Мәкаләләрнең эчтәлеге

**7 КЛАСС**

**Халык авыз иҗаты. Йола фольклоры.**

Йола фольклоры турында төшенчә. Йолаларның төрләре. Алар – халыкның рухи байлыгы, халыкны милләт итеп берләштерә торган асыл нигезләрнең берсе. Аларның көнкүреш һәм дини гореф-гадәтләр белән бәйләнеше, төрләре, үзенчәлекләре

**Гаилә йолалары.** Фәнис Яруллинның «Хәтерсез Күке» әкияте. Әкиятнең эчтәлеге. Күке образы.
Авторның ачышы. Халык әкиятләре уртак яклары.
«Төлке белән Алёнушка» әкияте белән уртак яклары.
Халык авыз иҗаты. Бәетләр. Бәетләрнең лиро-эпик жанр булуы. “Сак-Сок” бәете.
Кошларга әйләнгән ике бала язмышының фаҗигасе, бәетнең фантастик сюжетка корылган булуы
Мөнәҗәтләр. Мөнәҗәтләрнең лирик жанр булуы, аларның нигезендә ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Илаһи көчкә мөрәҗәгать итү, ялварып, ярлыкауны сорау икәнлеге турында мәгълүмат. Мөнәҗәтләрнең борынгы заманнардан ук татар язма әдәбиятының һәм халык иҗатының үзенчәлекле жанры булып формалашуы. “Туган ил исемнән китмәс” мөнәҗәтендә туган ил темасының бирелеше
Габдулла Тукай. Шагыйрь иҗаты турында белешмә. “Милли моңнар” шигыре.
Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе

**Аталар сүзе — акылның үзе**

Фатих Әмирхан. Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. “Ай өстендә Зөһрә кыз” әсәренең татар халык әкиятләренә нигезләнүе. Яхшылык белән явызлык көрәше.
Әдәбият теориясе. Әдәбиятта фольклоризм
Нәкый Исәнбәт. Язучы иҗаты турында белешмә. Халык авыз иҗатын җыюдагы хезмәтләре. “Җирән чичән белән Карачәч сылу” драмасы. Үзәк геройда халык авыз иҗатыннан килә торган сыйфатларның (җорлык, тапкырлык, акыл көче ярдәмендә дошманнарын җиңү) туплап бирелеше. Галимҗан Ибраһимов. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Алмачуар” хикәясе. Хайваннарга карата миһербанлылык хисләре тәрбияләү. Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре. Түбәтәй (кәләпүш), калфак, читек, чулпы, беләзек, изү турында мәгълүмат. Милли киемнәрнең үзенчәлеге, вакыт узган саен үзгәрүләргә бирелүе, халкыбыз үткән зур тормыш юлын, аның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыруы Роберт Миңнуллин. Шагыйрь турында белешмә. “Килен төшкәндә” шигыре. Халкыбызның гореф-гадәтләрен белү, аларга мәхәббәт тәрбияләү.
Рөстәм Яхин. Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Аның

профессиональ җырлар, романслар, музыкаль әсәрләр башкаруындагы эшчәнлеге. Рөстәм Яхин – Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторы

Халисә Мөдәррисова. Шагыйрәнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Көмеш дага” шигырендә бәхет төшенчәсенең тирән фәлсәфәсен ачуы. Сугыш фаҗигасенең чагылышы

**Ил язмышы — ир язмышы**

Әдип Маликов. Шагыйрь турында белешмә. «Ил язмышы — ир язмышы” шигырендә ватанпәрвәрлек билгеләре чагылу. Шигырьдә оптимистик рух.

Әдәбият теориясе. Гражданлык лирикасы. Пафос

Гадел Кутуй. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Сагыну” нәсере. Сугыштагы кешенең кичерешләрендә туган ил образы.

Әдәбият теориясе. Нәсер турында төшенчә. Инверсия

Сибгат Хәким. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Бакчачылар” поэмасы, “Бу кырлар, бу үзәннәрдә” шигыре. Әсәрләрдә лиризм, сәнгатьчә гадилек һәм осталык, ватанпәрвәрлек хисләре чагылышы

Рафаил Төхфәтуллин. Язучы турында белешмә. “Җиләкле аланнар” повестенда балачак хатирәләренең самимилеге, төгәллеге. Мәктәп тормышының үзенчәлекле детальләрдә чагылышы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтләрен бала күңеле һәм хисләре аша тасвирлау

Мөхәммәт Мәһдиев. Язучы турында белешмә. “Без — кырык беренче ел балалары” повесте (өзек). Бөек Ватан сугышы авырлыкларының әсәрдә чагылышы. Яшүсмерләр образы.

Әдәбият теориясе. Тартмалы композиция

Мөхәммәт Мирза. Шагыйрь турында белешмә. “Изге сукмак” шигыре. Балачак хатирәләренең онытылмавы, кешелеклелек сыйфатларының (мәрхәмәтлелек, изгелек, шәфкатьлелек) бирелеше.

**Һәр чорның үз герое**

Нәҗип Думави. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Беренче кар” шигыре. Табигатьнең матурлыгын тасвирлау

Һади Такташ. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Алсу” поэмасы. Яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләре чагылышы.

Әдәбият теориясе. Рефрен, кабатлау

Хәсән Туфан. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Агыла да болыт агыла”, “Тамчылар ни диләр?” шигырьләре. Чор белән бәйле шәхес фаҗигасе, хаксызга рәнҗетелгән кешеләр язмышы. Гурий Тавлин Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Кояш болытка кергәндә” романы (өзек). Әсәрдә фаҗигале елларның чагылышы. Чорның гаделсезлеген үз җилкәсендә татыган бала образы

**Туган җир ул була бер генә, туган җирнең кадерен бел генә!**

Аяз Гыйләҗев. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Өч аршын җир” повестеннан өзек. Туган җирнең кадерле булуы. Читтә яшәүчеләрнең туган туфракка тартылуы.

Илдар Юзеев. Шагыйрь турында белешмә. “Ак калфагым төшердем кулдан...” драмасы. Чит илләрдәге милләттәшләребез язмышы.

Әдәбият теориясе. Ремарка.

Фәннур Сафин. Шагыйрь турында белешмә. “Туган җиремә” шигыре. Туган якны ярату хисләренең бирелеше.

Марсель Галиев. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Нигез” повесте (өзек). Әсәрдә Бөек Ватан сугышы елларындагы вакыйгалар. Повестьта гореф-гадәтләрнең, йолаларның бирелеше. Туган җирнең, туган нигезнең кадерле, изге булуы, образларның бирелеше.

Әдәбият теориясе. Повесть

**Актыктан хаклык җиңә**

Фатих Хөсни. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Сөйләнмәгән хикәя” әсәре. Баланың күңел дөньясын сурәтләүдә язучының осталыгы. Мавыгу төшенчәсенә салынган мәгънәне ачыклау, үзеңә-үзең хуҗа булуның мөһимлеге.

Әдәбият теориясе. Тема турында төшенчә

Роза Хафизова. Язучы турында белешмә. “Әти кайткан көн” хикәясе. Бөек Ватан

сугышы чорында балалар язмышы
Фәнис Яруллин. “Ак төнбоек” хикәясе. Кешегә яхшылык эшләүнең күркәм гадәт икәнен, әмма аны һәрчак искә төшереп торуның кире тәэсир ясавын оста күрсәтү
Рафис Корбан. Шагыйрь турында белешмә. “Ярдәм итик” шигыре. Бал кортлары образы мисалында хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.
Рөстәм Галиуллин. Язучы турында белешмә. “Биш «икеле» хикәясе. Укуга, белем алуга уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, кимчелекләрне юмор аша күрсәтү
Айгөл Әхмәтгалиева. Язучы турында белешмә. “Табыш” хикәясе. Бала психологиясенең бирелеше, күркәм сыйфатлар тәрбияләү. Табылган әйбернең шатлык китермәвен аңлау

**Табигатькә дә табиб кирәк!**

Мөдәррис Әгъләмов. Шагыйрь турында белешмә. “Сөйли ак каен...” шигыре. Җанландырылган табигать образлары. Экологик тәрбия
Зиннур Мансуров. Шагыйрь турында белешмә. “Балык кычкыруы” шигыре. Елга-күлләребезнең пычрануы – кешелек дөньясы өчен зур фаҗига. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү
Хәбир Ибраһим. Язучы турында белешмә. “Карач” хикәясе. Кешеләрнең табигатьтәге җан ияләренә мөнәсәбәте

**8 КЛАСС**

**Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана**

Халык авыз иҗаты. Фольклор жанрлары буларак риваятьләр, аның ничек барлыкка килүе. Риваять төрләре.
Тарихи риваятьләр. Татар халыкының “Сихерче кыз” риваяте. Әсәрдә Казан образының бирелеше, тарихы. Әлеге риваятькә хас әкияти алымнар
Топонимик риваятьләр. Татар халкының “Гали тугае” риваяте. Урта гасыр Европа халкының “Моргана”риваяте. Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларының килеп чыгышы
Легендалар. Аның төрләре. Легенданың риваятьтән аермалы яклары.
Татар халкының «Зөһрә кыз» легендасы. Легендада Зөһрә образының бирелеше.
Әсәрдә хыял мотивлары, аның кеше язмышын ачудагы роле. Әсәрдә гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең бирелеше.
Музыка уен кораллары, аларның халык тормышындагы роле

**Без тарихта эзлебез**

Тарихи ядкарьләр буларак сәяхәтнамә һәм елъязма жанрлары. Ибне Фадлан – X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе. Ибн Фадланның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе. Болгар дәүләтенең ил тарихындагы роле. Ил башлыгы Алмыш хан. Фатих Кәрими. Әдип һәм журналист тормышы һәм иҗат юлы. Аның Европа илләренә сәяхәте, бу сәяхәтнең максаты. «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәреннән өзек. Европа илләрендәге культура учаклары, Петербург китапханәсе турында мәгълүмат. «Аурупа сәяхәтнамәсе»нең әдәби роле. Миргазиян Юныс. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Татар әдәбиятында диңгезчелек (маринистика) жанрына нигез салуы. Язучының “Су” хикәясе Әдәбият теориясе. Тарихи роман турында төшенчә
Тарихи һәйкәл буларак Казан Кремле, аның төзелү тарихы. Кремльнең бүгенге торышы.
Габдулла Тукай. Язучының 1895 нче елда Җаек (Уральск) шәһәренә китүе. Анда Тукайның җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалашуы. 1907 нче елда кире Казанга кайтуы. Шагыйрь иҗатының Казан чоры. Казанда аралашкан дуслары, балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнүгә керткән өлеше, театр эшчәнлегенә игътибары, сәяхәтләре, иҗтимагый эшчәнлеге. “Әл-ислах” газетасындагы эшчәнлеге. Габдулла Тукайның “Пар ат” шигыре. Аның язылу тарихы. “Пар ат” шигыренең лирик герое, аның кичерешләре, өметләре. Пар ат образының символикасы. Табигать, кучер образларының бирелеше, мәгънәләре.
Бакый Урманченың “Пар ат” шигыренә иллюстрациясе. Картинада Габдулла Тукай шигырендә сурәтләнгән вакыйганың бирелеше.
Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе. Премиянең беренче лауреатлары.
Күренекле рәссам, сынчы Бакый Урманченың (1897 – 1990) тормышы. Ул тудырган скульптур портретлар, картиналар.
Нажар Нәҗми. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы. Аның Тукай шәкерте булуы,

аның идеяләрен үстерүе. Н.Нәҗми иҗат иткән әсәрләрдә Тукай образының бирелеше, мәгънәсе. Шагыйрьнең «Татар теле» әсәрендә Тукай традицияләрен дәвам итүе. Н.Нәҗминең Бөек Болгарга сәфәре турындагы "Агыйделдә ак пароход" әсәреннән өзек. Әсәрдә сурәтләнгән "түгәрәк өстәл", анда катнашкан язучылар. Әсәрнең әдәби мәгънәсе, кыйммәте

**Онытылмас еллар**

Гариф Ахунов. "Замандашлар портреты" әсәреннән өзек. Язучының әсәрдә рәссам Виктор Куделькинның иҗатын яктыртуы, аның картиналары турында уйланулары. Рәссам иҗатында М.Җәлил образы, аның бирелеше, иҗатчының халык язмышының кискен дәверләрен полотнода сурәтләве. В.Куделькинның "Билгесез биеклектә" картинасы.

Сугыш турындагы җырлар. Роберт Әхмәтҗановның "Озатып вокзаллар каршында…" ("Солдатлар") шигыре. Сугышка баласын озаткан Ана образы. Татар халкының "Герман көе" җыры. Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуы һәм бер-берсенә йогынтысы.

Фатих Кәримнең тормышы, иҗаты. Аның иҗатында сугыш темасы, образларның бирелеше. Шагыйрьнең "Ант" шигыре, «азатлык» һәм «явызлык» проблемалары. "Кыңгыраулы яшел гармун" поэмасы, андагы образлар системасы. Гармун һәм җыр образының роле. Әлеге лирик әсәрләрдә сугыш проблемасының бирелеше

Туфан Миңнуллин. Күренекле драматург, язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең тормышы һәм иҗаты. "Моңлы бер җыр" драмасы. Әсәрдә М.Җәлил образының бирелеше, аның тоткынлыктагы тормышы. Драмада фәлсәфи мотивлар, фантастик алымнарның роле. Т.Миңнуллинның "Моңлы бер җыр" публицистик драмасы турында белешмә.

Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар.

Марсель Сәлимҗанов. Режиссёрның тормышы, иҗаты. Аның татар профессиональ театрының, милли драматургиянең үсешенә керткән өлеше.

Ринат Таҗетдинов. Халык артистының тормышы һәм иҗаты, ул тудырган онытылмас образлар.

Фронт хатлары, аның халык тормышындагы роле. Муса Җәлилнең кызы Чулпанга язган хаты, Фәтих Кәрим хатлары. Татар әдәбиятында эпистоляр жанр.

Әдәбият теориясе. Эпистоляр жанр турында төшенчә.

Мостай Кәрим. Шагыйрь һәм язучының тормышы, иҗаты. "Билгесез солдат" шигыре. Шигырьдә билгесез солдат образы. Лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы

Чыңгыз Айтматов. Әдип турында белешмә. Аның "Анам кыры" әсәре. Әсәрдә Тулганай, Җир-ана образлары. Җыелма Җир-ана образына салынган мәгънә. Авторның сугыш турындагы уйланулары. «Анам кыры» повесте турында белешмә.

**Әтинең зур бүреге иртә киелде**

Клара Булатова. Шагыйрә турында белешмә. "Башым иям" шигыре, сугыш афәтенең шагыйрәнең балачагына тәэсире, хатирәләрендә калдырган эзе.

Нур Әхмәдиев. Язучы иҗаты турында белешмә. "Җиңү көне" шигыре. "Минем туган көнем" хикәясе.

Факил Сафин. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Тулганай" әсәреннән өзекләр. Тулганай образы, аның әсәрдәге башка образларны ачудагы әһәмияте. Әсәрдә кешелеклек, шәфкатьлелек проблемалары.

Разил Вәлиев. Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. "Ватаным" шигыре. Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгы.

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан!**
**Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,**
**Туу кирәк кайчак безгә яңадан!**

Шәриф Камал. Әдипнең тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. "Буранда" новелласы. Төп геройның язмышы. Аның эчке дөньясы, күңел халәте. Психологик алымнар. Әсәрдә Ана образына хас сыйфатлар.

Әдәбият теориясе. Әдәби деталь. Матур әдәбиятта психологизм. Новелла турында төшенчә

Ибраһим Салахов. Язучының тормышы һәм иҗаты. Репрессияләнгән әдипләр язмышы. "Халык дошманы" төшенчәсе. "Ана тавышы" хикәясе ("Колыма хикәяләре"

циклыннан). Ялгыз ананың аяныч язмышы, кичерешләре. Автор әйтергә теләгән фикер
Сибгат Хәким. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. Иҗатында яктырткан темалар. “Әнкәй” шигырендә Ана образына хас сыйфатлар. Лирик геройның хис-кичерешләр бирелеше. Сагыну хисе. “Җырларымда телим” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы, сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар
Роберт Миңнуллин. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты. Әдәбиятка булган мәхәббәте.
Иҗатында яктыртылган темалар. “Әнкәй” шигыре. Ана образының бирелеше. Лирик геройның уйлары, кичерешләре.
Марсель Галиев. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре. Шигырьдә ана образы. Лирик геройның туган ягы турында хис-кичерешләре. “Кабатланмас әкият” шигыре. Хыялда туган авыл күренеше. Балачакка кайту теләге, лирик геройның хис-кичерешләре. Ана образының бирелеше Луиза Батыр-Болгари. Композиторның тормыш юлы, иҗаты.
Шәриф Хөсәенов. Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат. Беренче драмалары турында белешмә. “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы. Драмада ана образының бирелеше. Ананың язмышы, балаларына булган мәхәббәте. Автор әйтергә теләгән фикер. Шәриф Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы турында. Драманың татар әдәбиятында тоткан урыны. Ана образы турында мәгълүмат. Аналар һәм балалар проблемасы.
Фоат Садриев. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Таң җиле” романы. Романда бирелгән образларның язмышы, ана (Нуриәсма) образының бирелеше. Нәсимә белән Фәритнең үз-үзләрен тотышы, уллары Маратның авылда терелүе, сөйләшә башлавы, дуслар табуы. Авторның әйтергә теләгән фикере.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.
**Көлсәң – көл, еласаң – ела!**
Беренче сатирик журналлар. Беренче сатирик журналлар турында белешмә.
Вакытлы матбугатны башлап җибәргән шәхесләр.
Әдәбият теориясе. Сатира турында төшенчә
Галиәсгар Камал. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты, татар әдәбиятында тоткан урыны.
“Банкрот” сатирик комедиясе. Сиражетдин Туктагаевның тормыш, көнкүреше, уйлаган хәйләсе. Тирә-юньдәге образларның үз-үзләрен тотышы. Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе турында белешмә. Әсәрнең сәхнә тарихы. Әдип тарафыннан күтәрелгән проблема.
Әдәбият теориясе. Конфликт турында төшенчә. Сарказм. Проза әсәрләрендә сатира.
Гамил Афзал. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. Юмор-сатира өлкәсендә тоткан урыны “Юл газабы” хикәясе. Хикәяләүче авторның язмышы турында белешмә. “Тәвәккәл әби” шигыре. Әбинең аянычлы язмышы, эш-гамәлләре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы. Автор идеясе. Сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.
Әдәбият теориясе. Сатирик шигырь. Ирония турында төшенчә
Зәки Нури. “Пародия”. Пародиянең язылу стиле. Пародиягә салынган эчтәлек. Төрле шәхесләргә багышланган эпиграммалар. Эпиграммаларда сарказм.
Әдәбият теориясе. Пародия турында төшенчә. Эпиграмма
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау
**Даһи гомере – халкы хәтерендә!**
Ренат Харис. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Гармунчы” поэмасы. Поэманың эчтәлеге. Лирик геройның бирелеше. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Гармуннан чыккан көйләрнең сурәтләнеше. “Ике гөл” шигыре. Шигырьнең идеясе, төзелеше. Шигырьгә салынган мәгънә. Автор әйтергә теләгән фикер
Зөлфәт. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Юмор-сатира өлкәсендә ирешкән уңышлары. “Шигырем – ачык!” ,“Шундый чагы әле җанымның” шигырьләре. Аларда лирик геройның хис-кичерешләре. Әдип шигыренә хас үзенчәлекләр.
Әдәбият теориясе. Документаль повесть жанры.
Галия Кайбицкая. Актрисаның тормыш юлы турында белешмә. Татар музыка сәнгатен һәм операсын үстерүгә керткән өлеше.
Рабит Батулла. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Төрле жанрларда иҗат итүе. “Бию” кыйссасы. Рудик белән бәйле, госпитальдә булган көлкеле вакыйганың

әдәби гәүдәләнеше. Яшь талантның беренче уңышы.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау
**Табигатьнең дә җаны бар.**
Фәнис Яруллинның «Хәтерсез Күке» әкияте. Әкиятнең эчтәлеге. Күке образы.
Авторның ачышы. Халык әкиятләре уртак яклары.
«Төлке белән Алёнушка» әкияте белән уртак яклары.
**Ел дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**
**9 КЛАСС**
**Атадан улына чын мирас − сүздер**
**Халык авыз иҗаты. Дастаннар.**
Халык авыз иҗатының эпик жанры дастан турында төшенчә. Дастаннарның төрләре.
“Идегәй” дастаны. Аның төп герое. Дастанда тарихи шәхесләрнең сурәтләнүе. Әсәрдә ил белән идарә итү, халык язмышы мәсьәләсе.
Әдәбият теориясе. Халык авыз иҗаты. Дастан. Трагедия
Кол Гали язмышы. Аның “Кыйссаи Йосыф” поэмасы. Йосыфның язмышы. Туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр. Йосыф-Зөләйха мәхәббәте. Сюжетта кешеләрне ярату (гуманизм), гаделлек карашларының чагылышы. Поэмада төш күрү мотивлары.
Әдәбият теориясе. Рәдиф
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау
**Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә яши**
Сәйф Сараи иҗаты. Аның “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаныннан өзек. Әсәрнең сюжеты. Дастанда сурәтләнгән табигать күренешләренең роле. Чагыштыру, метафоралар, аларның оригинальлеге. Дөньяны материалистик аңлауны чагылдырган детальләр, аларның ышандыру көче. Геройларга характеристика бирү.
Әдәбият теориясе. Нәзыйрәчелек.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау
**Гөл үссә – җирнең күрке,**
Кыз үссә – илнең күрке
Габделҗаббар Кандалыйның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сахибҗамалга” поэмасы.
Шагыйрьнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы. Әсәрдә мәхәббәтнең чагылышы. Хатын-кыз гүзәллеген тасвирлауда шагыйрьнең табышлары
Ризаэтдин Фәхретдиннең тормышы турында белешмә. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” романында күтәрелгән проблемалар. Яхшылык һәм явызлык, әдәплелек һәм әдәпсезлек, галимлек һәм наданлык бәрелеше. Төп герой Әсма язмышы
Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында белешмә. Әдипнең Казан чоры иҗаты. “Татар кызларына” шигырендә күтәрелгән мәсьәләләр. Әсәрдә лирик геройның хисләрен ачыклау. Г.Тукайның татар кызлары турындагы хыял-өметләре. Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе. Казан шәһәрендә Габдулла Тукай музее турында мәгълүмат.
Әдәбият теориясе. Антитеза
Фатих Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты. Әдипнең күпкырлы иҗаты. “Хәят” повесте. Төп каһарман образы. Аңа хас сыйфатлар. Бай татар зыялыларының гаилә тормышы һәм гореф-гадәтләре. Шул шартларда үскән татар кызының холкы тәрбияләнү, омтылыш-теләкләре чагылу. Рус дөньясы белән аралашып үскән яшь кешенең дөньяга һәм яшәү тәртипләренә карашында каршылыклар туу. Кеше психологиясен тасвирлауда авторның осталыгы.
Аяз Гыйләҗевның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Аның “Җомга көн, кич белән...” повесте. Әсәрдә Бибинур образының бирелеше. Бибинур әбинең изге күңеллелеге, шәфкатьлелеге. Авторның кешеләрдә яхшылык, игелеклелек кебек сыйфатларның кими баруына борчылуы. Повестьның А.Солжиницинның «Матрёнин двор» әсәре белән уртак һәм аермалы яклары. Әсәрнең сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләнеше
Рөстәм Мингалим иҗаты. Шагыйрьнең прозасы “Сап-сары көзләр” хикәясе. Сугыш чоры кешеләренең язмышы, тормышы сурәтләнеше
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау
**Бер йөрәктә туган җыр икенче йөрәкне кузгата**
Әдәбият теориясе. Лирика. Пейзаж лирикасы.
Ркаил Зәйдулла турында белешмә. “Буранда” шигырендә сурәтләнгән табигать

күренеше. Шагыйрь хисләрен ачу юллары
Илсөяр Иксанова иҗаты. “Тузганак” шигырендә пейзаж бирелеше. Анда табигать
һәм кеше мөнәсәбәтләренең ачылышы.
Әдәбият теориясе. Гражданлык лирикасы
Сания Әхмәтҗанованың тормыш юлы һәм иҗаты. Аның “Татар акылы...” әсәрендә
күтәрелгән проблемалар. XX йөз башында Төркиягә киткән бөек шәхесләр турында
мәгълүмат бирү.
Әдәбият теориясе. Фәлсәфи лирика
Марс Шабаев тормышы һәм иҗаты. “Корыган имән монологы” шигырендә шагыйрьнең фәлсәфи карашларының чагылышы.
Мөхәммәт Мирза тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Иҗатына хас үзенчәлекләр. Робагый, газәл жанрындагы әсәрләре.
Әдәбият теориясе. Күңел лирикасы.
Фирүзә Җамалетдинованың иҗаты. Аның “Ташлар”, “Кунак көткән кебек”
шигырьләренең идея-проблематикасы.
Рәшит Әхмәтҗанов тормышы һәм иҗаты турында белешмә. “Сандугач керде
күңелгә” шигырендә шагыйрь хисләренең чагылышы.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**Театр – яктылыкка, нурга илтә!**

Галиәсгар Камал тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Драматург каләменә хас
сыйфатлар. “Беренче театр” комедиясендә конфликт һәм аның чишелеше, образларның
үзенчәлекле якларын ачу.
Әдәбият теориясе. Сүз уйнату. Монолог
Беренче хатын-кыз татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская иҗаты,
театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге.
Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында белешмә
Халисә Мөдәррисованың тормышы һәм иҗаты. “Бәйге хакы” повестеннан өзек
белән танышу. Язучының кеше язмышы турындагы ачыш-табышлары. Артистлар тормышын яктыртудагы яңалыгы. Аның сәхнә әсәре булып уйналуы.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау

**Мең шифага ия кулларда**

Күпме язмышларның эзе бар...
Габдрахман Әпсәләмовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Ак чәчәкләр” романында
күтәрелгән проблемалар. Әсәрдә табиблар һәм шәфкать туташларының хезмәтен чагылдыру үзенчәлеге.
Әдәбият теориясе. Роман. Хронотоп.
Саҗидә Сөләймpraнованың тормышы һәм язмышы турында белешмә. Әдинең
шигъри осталыгы. Шагыйрәнең прозасы. Табиблар тормышын чагылдырган “Гөлбадран”
повестеннан алынган “Дөнья бу!..” өзеге белән танышу. Сәламәтлек сагында торучы
табибларның үз эшләренә һәм кешеләргә мөнәсәбәте. Медицинада хирург хезмәте турында
сөйләшү.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау

**Укытучым! Синең бөек исемең**
**Йөрәгемдә мәңге сакланыр...**

Мөхәммәт Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗаты. Әдип каләменә хас сыйфатлар.
“Фронтовиклар” романында укытучылар тормышын һәм эшчәнлеген чагылдыру үзенчәлеге.
Төп герой Рушад образы.
Әдәбият теориясе. Тип.
Рәдиф Гаташның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Аның шигъри осталыгы.
Әсәрләренең жанры. “Укытучы” шигыре.
Лена Шагыйрьҗанның тормыш юлы һәм иҗаты. Шигърияткә алып килгән яңалыгы.
“Укытучы” шигырендә күтәрелгән проблемалар.
Вакыйф Нуриевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Инша” хикәясендә Әкрәм образының
бирелеше. Хикәядәге юморны аңлау.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**Авыр эшкә беләк бар,**

**Кыю эшкә йөрәк бар**

Хәсән Сарьянның тормыш юлы һәм иҗаты. Иҗатында лиризм. “Әткәм һөнәре” повестенда яшь кеше образын ачу үзенчәлекләре, аларда әхлакый сыйфатларның бирелеше.

Татар халкының борынгыдан килгән һөнәрләре турында белешмә бирү

Гариф Ахуновның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Иҗатында нефтьчеләр тормышын яктырту үзенчәлекләре. “Хәзинә” романында нефть чыгаручылар образлары.

Нефть табу белән бәйле һөнәрләр турында мәгълүмат бирү.

Әдәбият теориясе. Әдәби характер.

Илдар Юзеевның тормыш юлы һәм иҗаты. Аның шигъри һәм драматурглык осталыгы. “Таныш моңнар” поэмасында яшь кешенең тормыш юлын сайлауны чагылдыру.

Әдәбият теориясе. Поэма.

Хисам Камаловның тормыш юлы һәм иҗаты. “Очучы” хикәясендә күтәрелгән проблемалар. Очучы һөнәре турында мәгълүмат бирү.

Әдәбият теориясе. Мәдхия.

Мәдинә Маликованың тормыш юлы һәм иҗаты. “Казан каласы – таш кала” повестенда архитекторлар һөнәренә хас сыйфатларны чагылдыру үзенчәлеге

Салисә Гәрәеваның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Эшче һөнәрләрен ачу үзенчәлеге. “Сварщик егет” шигыре. Әдәбиятта тимерне эретеп ябыштыручылар образларын һәм эшчәнлеген гәүдәләндерү.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**